Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Талкышы авыл җирлеге Советы
карары

2025 елның 22 сентябре №1/5

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 10 февралендәге 29/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 24 июнендәге 158-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 10 февралендәге 29/1 номерлы Чистай шәһәр Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.1 статьяның 11 пунктының 1 пунктчасының 6 абзацында «гуманитар ярдәм,» сүзләреннән соң «халыкны яклауны тәэмин итү,» сүзләрен өстәргә, «китергән» сүзләреннән соң «яисә китерергә мөмкин» сүзләрен өстәргә;

1.2. 39 статьяның 2 өлешендә «составын һәм срокларын» сүзләрен «төзү тәртибе, составы һәм сроклары һәм» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Татар Талкышы авыл җирлеге
башлыгы М.М. Вәлиев